ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» июнь 2022 ел № 134

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңавыл авылында Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсендә бер башлангыч сыйныф-комплектны ябу турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының "Бер класс-комплектны кыскартуны вазифа ставкасын чыгару белән килештерү турында" 2022 елның 04 маеннан 565 номерлы үтенечнамәсен карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңавыл авылында Трисә урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсендә кече мәктәп яшендәге балалар саны кимүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңавыл авылында Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсендә бер башлангыч сыйныф-комплектны ябарга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең штат санын раслау турында» 2022 елның 16 маендагы 116 номерлы карары белән расланган «Педагогик, административ, укыту-ярдәмчел һәм хезмәт күрсәтүче персоналның штатлы саны» кушымтасының “Тирсә СОШ” 18 нче пунктына, түбәндәге вазыйфаларның штат берәмлекләрен төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә:

- «1» штат берәмлеге санында «укытучы» вазыйфасын бетерергә.

3. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе бацлыгына әлеге карар буенча оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**